ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.11.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№2175**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында

2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген (алга таба-исемлек) әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мөлкәт бары тик аны биләүгә бирү һәм (яисә) озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына файдалануга бирү максатларында, шулай ук 2008 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле нигездә читләштерелергә мөмкин дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
кушымта
16.11.2020 №2175

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеге

| № т/б | Мөлкәт реестрындагы номер | Адресы (урнашу урыны) корылма | Күчемсез милек объекты төре; күчемсез милек | Күчемсез милек яки аның өлеше турында мәгълүмат | | | | | | | | Күчемсез милек турында мәгълүмат | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Кадастр номеры | | Күчемсез милек дәүләт кадастры белешмәләре нигезендә күчемсез милек объектының бер өлеше номеры | Күчемсез милек объектының төп характеристикасы | | | Исәпкә алу объектының исеме | | | | | | |
| | | | | Номеры | Тибы (кадастр, шартлы, искергән) | | Тибы(мәйданы-җир участоклары, бинарлар, бүлмәләр өчен ; озынлыгы, күләме, мәйданы, яту тирәнлеге һ.б. - корылмалар өчен; озынлыгы, күләме, мәйданы, яту тирәнлеге һ.б. проект документациясе нигезендә төгәлләнмәгән төзелеш объектлары өчен) | Фактик әһәмияте/ проектлана торган әһәмият (төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары өчен) | Үлчәү берәмлеге (мәйданы-кв. м, озынлыгы-м;яту тирәнлеге өчен -м, күләме өчен-куб. м | | Тибы: җиһазлар, машиналар, механизмнар, урнаштыру, транспорт чаралары, инвентарь, инструментлар һ. б. | Дәүләт теркәү билгесе (булганда) | Исәпкә алу объектының исеме | Марка, модельне | Чыгарылган елы | Күчемсез милек объектының, шул исемтән объект урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 1 | 2 | 3 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 |
| 1 | | Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Большие Ключи авыл җирлеге, Малые Ключи авылы, Урман ур., з/у 3 | Җир кишәрлеге | 16:20:050301:44 | кадастр | з/у 3 | Мәйданы | 393 | кв. м. | ашханә | | | | | | |
| 2 | | Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Мулла Иле авыл җирлеге, Городище авылы, Залесная ур., 22а й. | Җир кишәрлеге | 16:20:240201:80 | кадастр | 22а йорты | Мәйданы | 137 | кв. м. | кибетне эксплуатацияләү өчен | | | | | | |
| 3 | | Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Карамалы Тау штп, Шоссе ур., 33 | Җир кишәрлеге | 16:20:020108:107 | кадастр | 33 | Мәйданы | 1200 | кв. м. | кибет төзү һәм эксплуатацияләү өчен | | | | | | |